*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№2 (56)

Ноябрь, 2023 нче ел

***Мөслим гимназиясенең 20 еллык юбилеена багышланган махсус чыгарылыш***

**Гимназиядә директор булып эшләгән шәхесләр:**



**Демидов Рафаэль Тимофеевич**

**2003-2006**



**Насырова Нәкыя Мирзанур кызы**

**2006-2014**



**Мирзаянов Азат Фәрит улы**

**2014 –2023**

## МӨСЛИМДӘ – БЕЛЕМ САРАЕ



2003 нче елның ноябрь аенда гимназиябез 3 нче урта мәктәп исеме белән тантаналы шартларда үз ишекләрен ачты. 840 укучыга исәпләнгән өч катлы мәктәпне ачу тантанасында Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, Татарстан мәгариф министры Фарис Харисов, Мөслим районы хакимияте башлыгы Ришат Хәбипов, мәгариф бүлеге мөдире Лена Нәҗмиева катнашты. Мөслим хуҗалыкара төзелеш оешмасы генераль директоры Илдар Авзалов символик ачкычын мәктәп директоры Рафаэль Тимофеевичка тапшырды.



Мәктәп район үзәгенә нур чәчеп, матурлык бөркеп тора. Бу тирәдә яши торган халыкның тәртибе дә һәр төбәккә үрнәк булырлык. Биредә укытучылар, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә булмасын, гаять зур оештыру эше башкаралар, безнең киләчәгебезне тәрбиялиләр, - дигән иде президентыбыз Минтимер Шәймиев укучыларны һәм укытучыларны яңа белем йортына аяк басулары белән котлап.



Бүгенге көндә "Мөслим гимназиясе" статусына ия булган уку йорты үзенең 20 еллык юбилеен билгеләп үтә.

## ГИМНАЗИЯГӘ ЕГЕРМЕ ЯШЬ!

Мөслим гимназиясенең укыту системасы районда гына түгел, республикабызда яхшылар рәтендә. Бу, әлбәттә, коллективның иҗади хезмәт, традицияләрне саклаган хәлдә укытуның инновацион формаларын урынлы һәм уңышлы кулланып белем бирү нәтиҗәсе. Без республика олимпиадалары, иҗади конкурслар, фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңү яулаучы укучыларыбыз һәм үз эшләренең чын осталары булган укытучыларыбыз белән горурланабыз.

Гимназия – бердәм эшләүче коллектив. Башлангычтан алып, югары сыйныфларга кадәр эзлеклелек, дәвамчылык саклана. Һәр ел саен йөздән артык укучының муниципаль олимпиадаларда җиңүче һәм призер булуы, республика олимпиадаларында, бөтенроссия, халыкара олимпиадаларда нәтиҗәләребез булу һәм ОГЭ, ЕГЭ күрсәткечләренең югары булуы – бердәм хезмәт нәтиҗәсе.




Безнең горурлыгыбыз - гимназия укучылары Баянов Шамил - 2022, Исмәгыйлова Лиана - 2023 нче елда химия һәм биология фәннәреннән 100 балл җыеп, 200 баллияләре булдылар.

Гимназиядә зур хезмәт куела. Илдә мәгариф тармагында туктаусыз реформалар үткәрелеп торса да, ул үз асылын югалтмыйча, алга таба эшчәнлеген тагын да арттыра, зуррак максатлар куеп, биегрәк үрләр яулау максатында эшли. Бездә сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү өчен бөтен мөмкинлекләр бар дип саныйм. Уку программалары камилләшә, алдынгы педагогик технологияләр кертелә, матди-техник база яхшыра. Укучылар күп төрле түгәрәкләрә, спорт секцияләренә тартылган. Проектлар, фәнни-тикшеренү эшләре өстендә эшләүче укучыларыбыз гимназиябез горурлыгы.

Чын күңелемнән гимназиябезнең 20 еллык юбилее белән котлыйм. Гимназия белән бәйле һәркемгә ныклы сәламәтлек, бетмәс энергия, рух күтәренкелеге, оптимизм телим.

Гимназия елъязмасында үз эзен калдырган шәхесләр – укытучыларыбыз һәм укучылар өчен бу зур бәйрәм, зур тантана.

*Ихтирам белән,*
*гимназия директоры*
*Мирзаянов Азат*
*Фәрит улы*

# ГИМНАЗИЯ: СЫЙФАТЛЫ БЕЛЕМ, ТӘРТИП, ЗАТЛЫЛЫК

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – Россиянең иң яхшы мәктәпләре исемлегендәге уку йорты.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – Россия “Мәгариф” өстенлекле милли проекты кысаларында инновацион белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү учреждениеләре конкурсы гранты иясе.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – "Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән



проектларны гамәлгә ашыруда муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына ярдәм итү" гранты иясе.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – Ризаэддин Фәхретдин исемендәге Республика премиясе иясе.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” һәм «Иң яхшы медицина кабинеты» Республика конкурслары җиңүчесе.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – өстәмә һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен стажировка мәйданчыгы.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – медицина сыйныфларын ачып, КДМУ белән хезмәттәшлек итүче.

**ГИМНАЗИЯ УЛ** – 557 укучы, 47 укытучы бердәмлеге.

## Сәләтле бала - мәктәп горурлыгы

**ГИМНАЗИЯ УЛ** - Бердәм дәүләт имтиханында районда югары 200 балл җыючы укучылары булуы белән дә данлыклы.



**2022 нче ел -**

***Шамил Баянов** химия һәм биология фәннәре буенча Бердәм дәүләт имтиханнарыннан йөзәр балл җыйды. Хәзер Санкт-Петербург дәүләт медицина университетының икенче курс студенты.*



**2023 нче ел –**

***Лиана Исмәгыйлова** химия һәм биология фәннәре буенча Бердәм дәүләт имтиханнарыннан йөзәр балл җыйды. Казан дәүләт медицина университетының беренче курсында белем ала.*

***Уңыш территориясе***

***Гимназияне 20 ел эчендә барлыгы 746 унберенче сыйныф укучысы тәмамлаган. Шуларның 116 сы «Укудагы аерым уңышлары өчен» медале һәм бик яхшы билгеләре белән аттестат алган.***

***Безнең медалистлар! Горурланабыз!***

***9 нчы сыйныфны тәмамлаган 993 укучының 86 сы кызыл аттестатка ия булган.***

# ЕГЕРМЕ ЕЛДАН СОҢ ГИМНАЗИЯ (УКУЧЫЛАРНЫҢ КҮЗАЛЛАУЛАРЫ)

*20* елдан соң мин гимназиябезне бик зур нәтиҗәләргә ирешкән, Республикада күренекле мәктәп итеп күз алдыма китерәм. Якын-тирә районнар арасында безнең гимназия - иң абруйлы, дәрәҗәле, конкурс үтеп керә укый торган, яхшы уку йортларына туры юл салучы мәктәп булачак.

Мәктәпне тәмамлаучылар бик дәрәҗәле җитәкчеләр, укытучылар, врачлар, юристлар, банкирлар, программистлар, эшмәкәрләр булырлар. Укытучыларыбыз безнең белән горурланып яшәрләр!

***Адилә Бәдертдинова***

*********

*20* елдан соң мин гимназияне инновацион белем бирү учреждениесы итеп күрәм.

Укытучылар командасы заманча һәм профессиональ булачак. Һәр укучыга индивидуаль якын килеп эшлиячәкләр. Укучылар



җәмгыятькә һәм әйләнә-тирә мохиткә уңай йогынты ясый торган проектларга җәлеп ителәчәк.

Гомумән алганда, минем мәктәбем яшьләрне уңышка алып барачак. Белемнәрне тиешле җирдә (тормышта, яшәештә) тиешле дәрәҗәдә куллана белүче укучылар, тышкы мохиткә тиз җайлашучы, анда аралаша белүче, функциональ грамоталы шәхесләр тәрбияләп чыгарачак.

***Биккинина Наилә***

*20* елдан соң, технологияләр һәм инновацияләр ярдәмендә безнең гимназия тулысынча үзгәрер дип уйлыйм. Уку һәр укучыга индивидуаль якын килүгә нигезләнәчәк. Укытучылар укучыларның уникаль сәләтләрен үстерүгә ярдәм итеп остаз ролен уйнаячак. Укучыларны тиз үзгәрә торган дөньяга һәм аларның киләчәк һөнәрләренә әзерләү өчен аралашу, хезмәттәшлек, проблемаларны дөрес итеп чишү кебек күнекмәләрне үстерүгә төп басым ясалыр дип уйлыйм.

Безнең туган тел проблемаларына килгәндә, мәктәп үз эченә төрле дәрәҗәдә туган телне өйрәнүне алган укыту программасын тәкъдим итәчәк. Бу программа, мәктәптә туган телен өйрәнә генә башлаган балаларга иркен аралашырга булышса, туган телләрендә иркен аралашучыларга тагын да күбрәк белер өчен файдалы булыр иде.

***Минһаҗева Диләрә***

# ҖЫЛЫ ТЕЛӘКЛӘР КАБУЛ ИТӘ ГИМНАЗИЯ

***Мәктәп - туган җир җылысын бирүче, балачак һәм үсмер еллар истәлеген саклаучы, еллар дәвамында үзенә чакырып, олылап каршы алучы изге йорт ул.***

***20 ел гомер....***

***Шушы елларда балалар укытуга зур өлеш керткән хөрмәтле ветеран укытучыларыбыз хатирәләре.***



## Юбилеең белән, гимназия!

Мәктәбебезнең егерме ел элек ачылуы бөтен Мөслим халкы өчен күтәп алынган шатлыклы вакыйга булды, чөнки укучылар ике сменада белем алалар иде. Ул көн бик нык истә: мәктәбебез ачылуга беренче президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев үзе килде. Мәктәп капка төбеннән үк, матур итеп киенгән балалар кулларына чәчәкләр, шарлар, флагчыклар тотып, “тере” коридор ясап кунакларны каршы алдылар. Мәктәп эчендә укытучылар, укучылар кабинетларда кунакларны көтеп торганы бүгенгедәй күз алдымда. Музыка кабинетында балалар Президентыбыздан матур шигырь юллары белән бассейн сорап, бассейнлы булдык.

Дирекция әгъзалары, коллектив эрудицияле, креатив, янып торалар иде. Бөтенесе дә яхшы идеялар белән янып йөриләр.



Яңа мәктәпне карарга кунаклар килү, ачык дәресләр, ачык чаралар бүгенгедәй күз алдымда. Әле кичә генә булган кебек. Рәхәт итеп эшләнде. Башта 3 нче мәктәп, аннары гимназия булса да берни үзгәрмәде, гел алдынгы булдык, алда бардык: районда да, республика күләмендә дә. Югары үрләр яулап, рәхәт, нәтиҗәле итеп эшләнде.

Мин шундый мәктәптә укытканыма бик сөенәм. Горурланам гимназия белән! Горурланам талантлы укучылары белән! Иң яхшы укытучылар, иң яхшы дирекция – гимназиядә!

***Зөлфирә Мөхәровна Саяхова***

## Гимназия белән горурланып яшим

Яраткан хезмәтемнең иң җаваплы, шул ук вакытта иң рәхәт булган унбиш елы шушында үткәнгәме, хәзерге вакытта 4 оныгым да шунда укыгангамы, бүгенге көндә Мөслим гимназиясе күңелемә бик якын. Гимназиямдә булган саен, күңелемдәге горурлык хисләре арткаННан-арта бара.



Гимназиябез директоры Демидов Рафаэль Тимофеевич җитәкчелегендәге коллегаларым белән бергә, заманча бинаны тизрәк сафка бастыру максаты белән, төнгә кадәр җыештырып, дәртләнеп эшләп йөргәнгә 20 ел үтеп тә киткән. Күпме хатирәләр...

Мөслим гимназиясендә эшләвем белән бик горурланам. 15 ел эчендә киңәшләшеп, бер-беребезне аңлап эшләгән, хезмәтемә зур бәя биргән гимназия директорлары Демидов Рафаэль Тимофеевич, Насырова Нәкыя Мирзануровна, Мирзаянов Азат Фәритовичка тирән рәхмәтле мин. Гимназия бүгенгедәй һәрвакыт алгы сафта, гел үсештә булсын иде.

***Хатирәләр белән тулырак танышу өчен***

***Маргарита Александровна Идиятуллина***

## Рәхмәт Сезгә укытучыларыбыз!



Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр безнең янәшәбездә һәрчак яраткан укытучыларыбыз атлый. Алар безне белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәтне яратырга өйрәтә.

Мин дә Мөслим гимназиясе укытучылары коллективына чиксез рәхмәтләремне җиткерәм. Аеруча, Ләйсән Фәһәметдин кызы белән Эльмира Васыйл кызына. Берсе биология фәненә мәхәббәт уятучы булса, икенчесе иҗат дөньясына “колагымнан тартып” алып керүче. Казан медицина университетында белем алганда, Ләйсән Фәһәметдинованың башлангыч салган нигезе ныклы булды, мин рәхәтләнеп укыдым. Шул ук вакытта туган телгә булган мәхәббәт мине төрле чараларда катнашырга этәрде.

Әле яңа гына гимназиядә белем алып йөргән идек. Укытучылар, шаушулы тәнәфесләр, дәрестән тыш чаралар – барысы да күз алдында.

***Язилә Әһлиуллина, гимназиянең 2017 нче ел чыгарылыш укучысы***

************

Мин – Мөслим гимназиясе укучысы. Минем һәрбер уңышым артында компетентлы укытучыларымның хезмәте ята.

Мөслим гимназиясе – белемле укучылар, талантлы яшьләр территориясе! Гимназия укучылары үзидарәсе эшчәнлегендә актив катнашуым миңа авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә, шатлыкларымны дусларым белән бүлешергә мөмкинлек бирә.

Мөслим гимназиясе – иҗат мәйданчыгы. Сәхнә осталыгы, сәхнә культурасы, сәнгатьле сөйләм, җыр сәнгатенә мәхәббәт, һәм, ниһаять, гимназиянең “ТЫЛСЫМ+” газетасы мөхәррире булу мөмкинлеге - миңа бары тик яраткан уку йортым тудырган мөмкинлекләр! Шундый мөмкинлекләрдән файдаланмау гаделсезлек булыр иде.

***Минһаҗева Камилә, “Тылсым +” газетасы мөхәррире***

# МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ – ИҖАТ МӘЙДАНЧЫГЫ



## ГИМНАЗИЯМ!

Өченче мәктәп – гимназиям минем,
Шундый якын, үз бит син!
Ярты Мөслим баласына
Белем биргән йорт бит син!

Матурландың, үзгәрдең син хәзер,
Ныклы белем өчен бар да әзер.
Халкым теләгәнчә, милли бул син,
Мөслимемнең йөзек кашы, рухы бул син!

Укучыларың бер дә онытмыйлар,
Районда син эзлесең.
Кыйбланы һич үзгәртмичә
Яңа юллар эзлисең.
Күп елларга шулай даның барсын,
Онытылмаслык хатирә калсын.

***Солтанова Алия,***
***гимназиянең 2023 нче ел чыгарылыш укучысы***

## БЕЗНЕҢ МӘКТӘП

Минем туган мәктәбем –
3 нче санлы мәктәп.
Бу шигыремдә язам
Үз мәктәбемне мактап.

Спортзалларда уйныйбыз
Көн саен тирләп-пешеп.
Сизелми үтә дәресләр
Йөгереп, мостик төшеп.

Тренажер залында да
Теләп шөгыльләнәбез.
Атнага бер көн дәрестә
Бассейнда йөзәбез.

Концерт-театр куябыз,
Кышын чаңгы шуабыз.
Шуңа күрә ярышларда
Без барсын да узабыз.

Укытучыларыбыз белемле,
Тырыш, уңган абый-апалар.
Безне кеше итәр өчен
Көнозын тырышалар.

Миллион сум да бирделәр –
Мәктәбебез тәртиптә.
Безнең уңышларны сөйләп
Бетереп булмый, һич тә.

***(25.05.2011 ел)***
***Эльза Гыйздәтова,***
***гимназиянең 2014 нче ел чыгарылыш укучысы***

## ДҮРТ ЕЛ ГОМЕР

*(башлангыч сыйныф укучыларына багышлана)*

Дүрт ел гомер ашыгып узып киткән,
Дүрт ел гомер – аккан су кебек.
Дүрт ел элек, әйе, дүрт ел элек
Без җиде ят, әле чит идек.

Шушы еллар акыл, белем бирде,
Дүрт ел бирде дусны, иптәшне.
Авыр чаклар булды, җиңеле дә, -
Бер-беребезгә бирдек киңәшне.

Дүрт ел гомер азмы, күпме икән?
Кыскадыр ул уйлап карасаң.
Исең китәр, калган эзләреңә
Бер әйләнеп карасаң.

Дүрт ел гомер ашыгып узып киткән,
Дүрт ел гомер – аккан су кебек.
Дүрт ел элек, әйе, дүрт ел элек
Без җиде ят, әле чит идек.

***Гөлназ Мирзасалихова,***
***югары категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы***

***20 яшь тулды мәктәбемә***
***Зур юбилей!***
***Узган зур гомер.***
***Ничә буын синдә белем алган,***
***Чистартылып агарган күңел.***






### Кадерле хатын-кызлар, әниләр һәм әбиләр – гимназия коллективының асыл затлары!

Сезне чын күңелдән иң җылы һәм күңелле бәйрәмнәрнең берсе – Әниләр көне белән котлыйбыз!

Әниләр көнен бәйрәм итү - ул әниләрнең безнең өчен эшләгән бар нәрсәсе, аларның мәхәббәте һәм аңлавы өчен үз рәхмәтеңне һәм чиксез мәхәббәтеңне белдерү өчен бик яхшы мөмкинлек. Кадерле гаилә традицияләрен саклаучылар, армый-талмый куйган хезмәтегез, чиксез сабырлыгыгыз, рухи юмартлыгыгыз өчен сезнең алда баш иябез! Укыту-тәрбия процессына Сезнең һәрберегезнең чиксез зур өлеше керә.

Кадерле әниләр! Армый-талмый куйган хезмәтегез, чиксез сабырлыгыгыз, күңел юмартлыгыгыз өчен рәхмәт, мәхәббәт һәм хөрмәт сүзләрен кабул итегез. Сезнең күзләрегездә елмаюлар сүнмәсен! Сезгә сәламәтлек, бәхет, гаилә иминлеге, үзара аңлашу һәм җавап итеп балаларыгыздан җылылык телибез!

***Мөслим гимназиясе укучылар үзидарәсе***

ТЫЛСЫМ+
Ноябрь, 2023 нче ел
№2 (56)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100